| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ<br>ЧЕРЕМШАНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100 | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ<br>Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100 |

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

12.12.2023 ел №219

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә класслы чиннар бирү тәртибе һәм аттестация үткәрү тәртибе турында» 2022 елның 31 мартындагы №101 Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы № 25-ФЗ Федераль закон, 2013 елның 30 маендагы № 50-ТРЗ Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 02 ноябрендәге № 99-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә сыйныф чиннарын бирү тәртибе һәм аттестация үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәләрне раслау турында» 2022 елның 31 мартындагы №101 Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы карарына яңа редакциядә бәян итеп үзгәреш кертергә: «6.2. Муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турында карар, Нигезләмәнең 2.3 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, органга яки җирле үзидарәнең класс чинын бирергә вәкаләтле вазыйфаи затына барлык кирәкле документлар белән класс чины бирү турында тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш».

2. Әлеге карарны рәсми хокукый мәгълүмат порталында (Pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башлыгы урынбасарына, Совет рәисе урынбасарына йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов